**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр  авылында 2025 елда гражданнардан үзара салым кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2024 елның 22 ноябре** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы  Келәр  авылындагы гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең  Келәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, тавыш бирү хокукына ия яшәү урыны буенча теркәлгән ,бәлигъ  булган һәр гражданнан 2025 елда 10 000 (ун мең) сум күләмендә үзара салым кертергә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны  расларга:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең  Малаевка  торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, тавыш бирү хокукына ия ,яшәү урыны буенча теркәлгән ,бәлигъ булган һәр гражданнан 2025 елда 10 000 (ун мең) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү.

«РИЗА"                                "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат такталарында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы  Карамалы ав., Үзәк  ур., 4 й.
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай ур., 16 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы ,
гражданнар жыенында рәислек итүче: Э.И.Байдамшин